| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ӘЛМӘТ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОН СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«11» марта 2021 г. г. Альметьевск № 44

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының «Хайван авыруларын кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, халыкны кеше һәм хайваннар ечен уртак чирләрдән яклау чараларын үткәрүне оештыру елкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча вәкаләтле орган турында» 2013 елның 07 февралендәге 273 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру елкәсендә, шулай ук хайваннар белән эш итү елкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2012 елның 13 гыйнварындагы 9-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының «Хайван авыруларын кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, халыкны кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча вәкаләтле орган турында» 2013 елның 07 февралендәге 273 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Хайван авыруларын кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, халыкны кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән яклау чаралар үткәрүне оештыру, шулай ук хайваннар белән эш итү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча вәкаләтле орган турында»;

1.2. Карар преамбуласында ««Муниципаль районнарның һәм «Чаллы шәһәре» шәһәр округының җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым

Заказ № 2625

дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2012 елның 13 гыйнварындагы 9-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы» сүзләрен ««Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә, шулай ук хайваннар белән эш итү өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2012 елның 13 гыйнварындагы 9-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы» сүзләргә алмаштырырга;

1.3. Карарның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетын хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак булган авырулардан халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру елкәсендә, шулай ук хайваннар белән эш итү елкәсендә Татарстан Республикасының түбәндәге дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча вәкаләтле орган итеп билгеләргә:

- себер түләмәсе (язва) үләт базларын һәм биотермик чокырларны (алга таба - объектлар) тоту, шул исәптән аларны төзекләндерү, гамәлдәге законнар нигезендә тиешле санитар халәткә китерү;

- объектларның иминлеген тәэмин итү буенча чаралар күрү;

- биотермик чокырларны консервацияләү;

- хуҗасыз хайваннар белән эш итү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашырганда чаралар оештыру».

2. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны районның икътисадый үсеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм муниципаль милек мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә, район Советының аграр мәсьәләләр, табигый ресурслар һәм экологик иминлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов